ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Хезмәт ветераны» исемен бирү тәртибе һәм шартлары турында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәреш кертү хакында» 96-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары О.М. Воронова, Р.С. Гайнетдинова, С.М. Захарова, Е.И. Кузьмичева, Л.Н. Маврина тарафыннан кертелгән «Хезмәт ветераны» исемен бирү тәртибе һәм шартлары турында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәреш кертү хакында» 96-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре
2025 елның 25 сентябре
№ 407-VII ДС

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы
депутатлары
О.М. Воронова,
Р.С. Гайнетдинова,
С.М. Захарова,
Е.И. Кузьмичева,
Л.Н. Маврина
тарафыннан кертелә

**«Хезмәт ветераны» исемен бирү тәртибе һәм шартлары турында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәреш кертү хакында»**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Хезмәт ветераны» исемен бирү тәртибе һәм шартлары турында» 2011 елның 30 июнендәге 33-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 2 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2011, № 6 (I өлеш), № 10 (I өлеш) ); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 3 (I өлеш), аңа «башка федераль дәүләт органнары,» сүзләреннән соң «Россия Федерациясе Үзәк банкы (Россия Банкы),» сүзләрен өстәп, үзгәреш кертергә.

**2 статья**

1. Әлеге Закон 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.
2. «Хезмәт ветераны» исемен бирү тәртибе һәм шартлары турында» 2011 елның 30 июнендәге 33-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы нигезләмәләрнең гамәлдә булуы (әлеге Закон редакциясендә) әлеге Закон үз көченә кергән көннән соң «Хезмәт ветераны» исеме бирелү хокукын бирә торган ведомство аерымлык тамгасы белән әлеге Закон үз көченә кергән көнгә кадәр бүләкләнгән затларга да кагыла.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Хезмәт ветераны» исемен бирү тәртибе һәм шартлары турында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына**

# АҢЛАТМА

«Хезмәт ветераны» исемен бирү тәртибе һәм шартлары турында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты Россия Федерациясе Үзәк банкы (Россия Банкы) тарафыннан гамәлгә куелган ведомство аерымлык тамгалары белән бүләкләнгән затларга «Хезмәт ветераны» исеме бирелүне күздә тота торган «Ветераннар турында» Федераль законның 7 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2025 елның 1 апрелендәге 53-ФЗ номерлы Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә эшләнде.

Закон проекты белән «Хезмәт ветераны» исемен бирү тәртибе һәм шартлары турында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 2 өлешенә шундый ук үзгәреш кертү тәкъдим ителә һәм 1 статьядагы нигезләмәләрнең гамәлдә булуы (өстәлгән редакциядә) шул исәптән әлеге Татарстан Республикасы Законы үз көченә кергән көннән соң «Хезмәт ветераны» исеме бирелү хокукын бирә торган ведомство аерымлык тамгасы белән закон үз көченә кергән көнгә кадәр бүләкләнгән затларга да кагыла.

Әлеге Татарстан Республикасы Законының үз көченә керү вакыты 2026 елның 1 гыйнвары дип тәкъдим ителә (югарыда күрсәтелгән Федераль законның үз көченә керү датасы кебек).

**«Хезмәт ветераны» исемен бирү тәртибе һәм шартлары турында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалтуы танылырга, туктатып торылырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

# ИСЕМЛЕГЕ

«Хезмәт ветераны» исемен бирү тәртибе һәм шартлары турында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы законнарының һәм башка норматив хокукый актларының үз көчләрен югалтуын тану, аларны туктатып тору, үзгәртү яисә яңаларын кабул итү таләп ителми.

**«Хезмәт ветераны» исемен бирү тәртибе һәм шартлары турында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын**

**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Хезмәт ветераны» исемен бирү тәртибе һәм шартлары турында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми.